

Һонәрчелек тошенчәсенә бик кvп кызыклы дәресләр керә - чигv, бәйләv, макраме, бортек бәйләv, рәсем ясау. Мондый хобби белән шогыльләнv дулкынландыргыч кына тvгел, ул нерв системасы очен дә искиткеч ял итv.
Мәсәлән, декупаж яки скрепбукинг тынычландыра һәм хәзерге проблемаларны оныт ырга момкинлек бирә. UNHECKO хәтта һонәрне ботендонья мәдәни мирасы исемлегенә кертә, чонки анын кvп торләре юкка чыгарга момкин. Чыннан да, безнен әби-бабайлар буш вакытларын йоннан әйберләр бәйләvгә, чигvгә, тукуга багышлаганнар. Яратып эшләнгән матур эшләре – ашъяпкычлар, картиналар, шәлләр, кәрзиннәр - йортларда сакчыл сакланган һәм буыннан-буынга тапшырылган. Безнен кvбебездә әби белән бәйләнгән кулъяулык яки мендәр тышлары, талчыбыктан vрелгән кәрзиннәр яисә агачтан ясалган савыт-саба, чабаталар саклана.      16 ноябрьдә, хатын-кызларны кул эшләре белән кызыксындыру максаты белән, Ботендонья һонәрчелек конендә (World Needlework Day) Ләмберә районы Аксён мәдәният йорты хезмәткәрләре кул эшләреннән кvргәзмә оештырды. Әйтеп китәргә кирәк, бvген кул эшләре дәресләре очен бик кvп момкинлекләр бар - махсус кибетләрдә торле жайланмалар сатыла: энже-мәржәннәр, жеп, йон, спицалар... Ә яна гына кул эшләре белән мавыга башлаган кешеләр очен, мәсәлән, номерлары буенча картиналар яки аппликацияләр тәкъдим ителә.
Шулай, гомер буе педагогика белән унышлы шогыльләнгән Аксен урта мәктәбе укытучылары Луиза Абдрахман кызы Равилова һәм Наилә Муся кызы Юсупова лаеклы ялларында да активлар: кем картина ясый, кем торле жепләрдән матур-матур әйберләр бәйли. Клуб хезмәткәрләре vзләре дә булдыклылар – зур сәхнәләрдә жырлыйлар, кул эшләре осталары буларак, тәмле ашлар пешерәләр, бисер белән дуслар, рәсемнәр дә ясыйлар. Хәтта кvргәзмәләрдә дә катнашып унышларга ирешәләр.

**Н.ХӘЛИЛ**